ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 393-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.А. Якунин, К.Ә. Ногаев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 393-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 22 феврале
№ 1843-VI ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
Л.А. Якунин,
К.Ә. Ногаев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 22 статьяның 1 пунктындагы икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

2) 23 статьяның 1 пунктындагы икенче абзацында «шартнамәләр (килешүләр)» сүзләреннән соң «, шул исәптән инфраструктураны бергә үстерү өчен регионара хезмәттәшлек турындагы килешүләр» сүзләрен өстәргә;

3) $23^{1}$ статьяның 1 пунктындагы икенче абзацында «шартнамәләр (килешүләр)» сүзләреннән соң «, шул исәптән инфраструктураны бергә үстерү өчен яклары шәһәр округы булган муниципальара хезмәттәшлек турындагы килешүләр» сүзләрен өстәргә;

4) $29^{3}$ статьяда:

а) 2 пунктта «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 һәм 104 статьялары,» сүзләрен «әлеге статьяның 3 – 5 пунктлары, шулай ук», сүзләренә

алмаштырырга, «, инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының тиешле ел ахырына файдаланылмаган калдыгы күләменнән тыш,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Финанс хисабы елында Татарстан Республикасы хисаплашуларының гомуми суммасы Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын һәм Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәрен финанслауга юнәлдерелгән акчаларның гомуми суммасыннан финанс хисабы елы ахырына, алардан файдалану шартлары билгеләнеп бирелгән, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән максатчан билгеләнешкә ия бюджетара трансфертлардан, юридик затлардан максатчан билгеләнешкә ия кире кайтарылмый торган акчалардан, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары баланслылыгын тәэмин итү чараларына ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетына дотацияләрдән тулысынча файдаланмауга бәйле рәвештә барлыкка килгән калган акчалар күләменә, шулай ук финанс хисабы елының ахыргы эш көненнән соң Татарстан Республикасы бюджетына күчерелгән, шул исәптән акчаларның ахыргы әйләнешләрен үткәрү тәртибендә, финанс хисабы елы керемнәре акчалары күләменә артыграк булырга мөмкин.

Акчаларның ахыргы әйләнешләре дигәндә, финанс хисабы елына караган, әмма агымдагы финанс елы башында Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны тапшыруның билгеләнгән срогына кадәр үткәрелгән счетлар буенча акчалар әйләнешләре (алга таба әлеге статьяда – акчаларның ахыргы әйләнешләре) аңлашыла.

Финанс хисабы елында Татарстан Республикасы хисаплашуларының гомуми суммасы Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын һәм Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәрен финанслауга юнәлдерелгән акчаларның гомуми суммасыннан, финанс хисабы елы йомгаклары буенча әлеге пунктның беренче абзацында каралган ихтимал булган арттыруларны исәпкә алып, артып киткән очракта, агымдагы финанс елының 1 гыйнварына барлыкка килгән Татарстан Республикасы бюджетының күрсәтелгән арттыру суммасындагы калган акчалары әлеге Кодексның 25 статьясындагы 3 пунктында каралган максатларга, агымдагы финанс елына хисаплашуларның иң чик күләмен киметеп, юнәлдерелергә тиеш.»;

в) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Финанс хисабы елында муниципаль берәмлек хисаплашуларының гомуми суммасы җирле бюджет кытлыгын һәм муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәрен финанслауга юнәлдерелгән акчаларның гомуми суммасыннан финанс хисабы елы ахырына, алардан файдалану шартлары билгеләнеп бирелгән, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән максатчан билгеләнешкә ия бюджетара трансфертлардан, юридик затлардан максатчан билгеләнешкә ия кире кайтарылмый торган акчалардан, Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетлар баланслылыгын тәэмин итү чараларына ярдәм күрсәтүгә җирле бюджетларга дотацияләрдән яисә җирле бюджетларга башка дотацияләрдән тулысынча файдаланмауга бәйле рәвештә барлыкка килгән калган акчалар күләменә, шулай ук финанс хисабы елының ахыргы

эш көненнән соң җирле бюджетка күчерелгән, шул исәптән акчаларның ахыргы әйләнешләрен үткәрү тәртибендә, финанс хисабы елы керемнәре акчалары күләменә артыграк булырга мөмкин.

Финанс хисабы елында муниципаль берәмлек хисаплашуларының гомуми суммасы җирле бюджет кытлыгын һәм муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәрен финанслауга юнәлдерелгән акчаларның гомуми суммасыннан, финанс хисабы елы йомгаклары буенча әлеге пунктның беренче абзацында каралган ихтимал булган арттыруларны исәпкә алып, артып киткән очракта, агымдагы финанс елының 1 гыйнварына барлыкка килгән җирле бюджетның күрсәтелгән арттыру суммасындагы калган акчалары әлеге Кодексның 25 статьясындагы 5 пунктында каралган максатларга, агымдагы финанс елына хисаплашуларның иң чик күләмен киметеп, юнәлдерелергә тиеш.»;

г) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына бюджет кредитлары бирү тәртибендә җирле бюджетларга бюджет кредитлары, шулай ук инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет кредитлары бирү каралган булса, Татарстан Республикасы бюджетына бирелгән әлеге бюджет кредитларына күрсәтелгән статьяның 2 һәм 3 пунктлары нигезләмәләре кагылмый.»;

5) 31 статьяның $4^1$ пунктында:

а) «Татарстан Республикасы дәүләт бурычының күләме» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасына карата Россия Федерациясе Бюджет кодексының 130 статьясындагы 4 пунктында каралган чаралар гамәлгә ашырылган очрактан тыш)» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасына карата Россия Федерациясе Бюджет кодексының 130 статьясындагы 4 пунктында каралган чаралар гамәлгә ашырылган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт бурычының күләме Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт бурычының иң югары чигеннән, шул исәптән эчке дәүләт хисаплашулары программасы күрсәткечләреннән, федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бирелгән бюджет кредитлары суммасына артыграк булырга мөмкин, әмма чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты хакындагы Татарстан Республикасы законы белән расланган, кире кайтарылмый торган акчаларның расланган күләмен исәпкә алмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең гомуми күләменең 100 процентыннан артмаска тиеш.»;

6) $44^{2.1}$ статьяның 1 пунктында «финанслашу максатларында» сүзләреннән соң «, шул исәптән аларны төзү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнә торган инфраструктураны бергә үстерү

өчен регионара хезмәттәшлек турында төзелгән килешүләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында» сүзләрен өстәргә;

7) $44^5$ статьяның $4^2$ пунктындагы икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасының җирле бюджетларга җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен башкаруга финанс ярдәме күрсәтү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирү буенча чыгым йөкләмәсе финанслашкан очракта, әлеге килешүләр Россия Федерациясе Бюджет кодексының $132^1$ статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән килешүләр өчен Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган типлаштырылган рәвеш кебек үк рәвеш буенча төзеләләр.»;

8) $44^{11}$ статьяның 1 пунктында «финанслашу максатларында» сүзләреннән соң «, шул исәптән аларны төзү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый актлары белән билгеләнә торган инфраструктураны бергә үстерү өчен яклары шәһәр округы булган муниципальара хезмәттәшлек турында төзелгән килешүләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында» сүзләрен өстәргә;

9) 45 статьяның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

10) 49 статьяда:

а) икенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) илле җиденче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

11) $51^1$ статьяның 2 пунктындагы беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

12) 53 статьяның 2 пунктындагы 2 пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

13) $53^3$ статьяның 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

14) 60 статьяның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

15) 61 статьяның 1 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

16) 63 статьяда:

а) 3 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

17) 67 статьяда «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

18) 69 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

19) 70 статьяда:

а) икенче абзацта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче абзацта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

20) 71 статьяның исемендә һәм текстында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

21) 78 статьяның 3 пунктында:

а) беренче абзацта «кабул итә» сүзләреннән соң «һәм элек кабул ителгән бюджет йөкләмәләренә үзгәрешләр кертә» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бюджет акчаларын алучы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка федераль законнар нигезләмәләрендә каралган очракларда, дәүләт контрактлары, башка шартнамәләр буенча йөкләмәләрне бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогыннан соң башкару каралган мондый дәүләт контрактлары, башка шартнамәләр төзи.»;

22) 93 статьяның 3 пунктындагы икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

23) $97^4$ статьяның 1 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

24) $97^6$ статьяның 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2009 елның 4 июлендәге 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (II өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш), «2025 елның» сүзләрен «2026 елның» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 23 статьяның 1 пунктындагы икенче абзацы, $23^{1}$ статьяның 1 пунктындагы икенче абзацы, 31 статьяның $4^{1}$ пункты, $44^{2.1}$ статьяның 1 пункты, $44^{5}$ статьяның $4^{2}$ пунктындагы икенче абзацы, $44^{11}$ статьяның 1 пункты нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетын үтәгәндә барлыкка килүче хокук мөнәсәбәтләренә 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетыннан башлап кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Закон проекты Татарстан Республикасы Бюджет кодексын «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 19 декабрендәге 521-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 28 декабрендәге 562-ФЗ номерлы (алга таба – 562-ФЗ номерлы Федераль закон) Федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

Закон проектында Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $29^3$ статьясына үзгәрешләр кертү каралган, алар нигезендә финанс хисабы елында Татарстан Республикасы хисаплашуларының гомуми суммасы Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын һәм Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәрен финанслауга юнәлдерелгән акчаларның гомуми суммасыннан хисап елы ахырына, алардан файдалану шартларын билгеләнеп бирелгән, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән максатчан билгеләнештәге бюджетара трансфертлардан, юридик затлардан максатчан билгеләнештәге кире кайтарылмый торган акчалардан, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары балансдылыгын тәэмин итү чараларына ярдәм күрсәтүгә дотацияләрдән тулысынча файдаланмауга бәйле рәвештә барлыкка килгән калган акчалар күләменә, шулай ук финанс хисабы елының ахыргы эш көненнән соң Татарстан Республикасы бюджетына күчерелгән, шул исәптән акчаларның ахыргы әйләнешләрен үткәрү тәртибендә, финанс хисабы елы керемнәре акчалары күләменә артыграк булырга мөмкин.

Шундый ук нормаларны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре өчен билгеләү тәкъдим ителә.

Закон проектында Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 23 һәм $23^1$ статьяларына, Татарстан Республикасы һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге чыгым йөкләмәләре шулай ук инфраструктураны бергә үстерү өчен регионара һәм муниципальара хезмәттәшлек турындагы килешүләр төзү нәтиҗәсендә барлыкка килүен билгеләп, үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

Бер үк вакытта закон проектында Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{2.1}$ һәм $44^{11}$ статьяларына, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары һәм җирле бюджетлар арасында «горизонталь» субсидияләр шул исәптән инфраструктураны бергә үстерү өчен регионара һәм муниципальара хезмәттәшлек турында төзелгән килешүләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында бирелергә мөмкин дип билгеләп, үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

Моннан тыш, закон проектында Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешүләр

һәм федераль бюджеттан җирле бюджетларга җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен башкаруга финанс ярдәме күрсәтү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәсе финанслашкан очракта, әлеге килешүләргә өстәмә килешүләр Россия Федерациясе Бюджет кодексының $132^1$ статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән килешүләр өчен Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган типлаштырылган рәвеш кебек үк рәвеш буенча төзеләләр.

Закон проектында Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 78 статьясына үзгәреш кертү күздә тотыла, аның нигезендә Россия Федерациясе Бюджет кодексының бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогыннан артык срокка тиешле бюджет акчалары исәбеннән үтәлергә тиеш йөкләмәләрне кабул итү очраклары турындагы нигезләмәләре шулай ук элек кабул ителгән дәүләт контрактларына (муниципаль контрактларга), башка шартнамәләргә үзгәрешләр керткәндә дә кулланыла.

562-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2009 елның 4 июлендәге 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертелә, ул чик срокны озайтуны (2025 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 1 гыйнварына) күздә тота, аңа кадәр муниципаль бурыч территорияләрендә халыкара спорт ярышлары үткәрелгән, аларны үткәрү турында карарлар Россия Федерациясе Президенты һәм (яисә) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән, бюджетларында хисап елында Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан дотацияләр өлеше 2017 елның 1 гыйнварына муниципаль бурыч күләме, кире кайтарылмый торган керемнәрнең һәм (яисә) түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәреннән акча керүләрнең расланган күләмен исәпкә алмыйча, җирле бюджет керемнәре күләменең 100 процентыннан артыграк булган җирле бюджетларның үз керемнәре күләменең 5 процентыннан артмаган муниципаль берәмлекләргә карата агымдагы елның 1 гыйнварына торышы буенча реструктурлаштырылган бюджет кредитлары буенча муниципаль бурыч күләме чикләрендә Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән чикләүне арттыра ала.

Моннан тыш, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә закон проекты белән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезләмәләренә Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты вазыйфасы исеме өлешендә үзгәрешләр кертү каралган.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү инфраструктураны бергә үстерү өчен регионара хезмәттәшлек турындагы килешүләрне төзү тәртибен раслау турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актын кабул итүне таләп итәчәк.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен киметүгә китерми һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.